**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы һәм 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Эшкә урнаштыру үзәкләрендә исәптә торучылардан булган инвалидларны эшкә урнаштырудан баш тарту очраклары саны, берәмлек»;

б) 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 Производство белән бәйле фаҗигале хәлләр нәтиҗәсендә һәлак булучылар санының узган ел белән чагыштырганда кимү темпы, процент»;

в) 4.2 һәм 7 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

г) «***» символы белән билгеләнгән искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*** Күрсәткеч, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән кала, федераль башкарма хакимият органнарының барлык территориаль органнарына карата кулланыла.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 29 март
№ ПУ-189